**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.01.2026 № 100

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Нурлат муниципаль районы Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 02 ноябрендәге 885 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган су объектларында гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнары билгеләү методикасына үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 26 сентябрендәге 763 номерлы карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы «Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2020 елның 02 ноябрендәге 885 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районының «Гражданнарны яклау идарәсе» МКУ хезмәткәрләренең гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 4 пунктына (Татарстан

Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 июлендәге 707 номерлы, 2024 елның 16 декабрендәге 1523 номерлы карары белән үзгәрешләр белән)аны түбәндәге редакциядә бәян итеп үзгәрешләр кертергә:

4. Хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары 1нче таблицада китерелгән:

| № т\с | Хезмәткәрләрнең вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1. | Учреждение җитәкчесе | 33 345 |
| 2. | Оператив кизү торучы | 25 650 |

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин